**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

425 №                                    2018 нче ел « 29 »  октябрь

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2017 елның 5 декабрендә кабул ителгән
«2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районында дәүләт
милли сәясәтен гамәлгә ашыру
муниципаль программасын раслау турында»
494 номерлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 5 декабрендәге “2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау " ярдәмче программасын гамәлгә ашыру зарурлыгы максатларында, Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 26 апрелендәге ПР-1069 номерлы карары белән расланган “2013-2018 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планы”на туры китереп, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия утырышының 2016 елның 18 декабрендәге ПР-392 номерлы беркетмәсенең 1.12 пунктын үтәү йөзеннән Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 5 декабрендәге 494 номерлы карары белән расланган “2017-20 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау"ярдәмче программасын (алга таба - Ярдәмче программа) кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 5 декабрендәге 494 номерлы карары белән расланган “2017-20 елларга Татарстан

Республикасы Әлки муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау"ярдәмче программасын үз көчен югалткан дип таныrга.

3.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесендә ел саен чираттагы финанс елына Әлки муниципаль районы бюджетын формалаштырганда, әлеге максатларга Әлки муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган мөмкинлекләрне һәм акчаларны исәпкә алып Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга акча каралырга тиеш.

4.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруда катнашырга тәкъдим итәргә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

6.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе — Йосыпов И.В.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе карарына
кушымта

_____№   2018 нче ел «___» _________

# “ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА 2017-2020 нче елларда ТЕРРОРИЗМ ҺӘМ ЭКСТРЕМИЗМНЫ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ” ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫ

Базарлы Матак авылы

## Ярдәмче программаның Паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | "Әлки муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау "( алга таба Ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказчы | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Әлки муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе |
| Ярдәмче программаның максаты | Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын, экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору нигезендә аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен, районда андый күренешләрне профилактикалау һәм кисәтү дәрәҗәсен күтәрү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ туфракта конфликтларны кисәтү һәм булдырмау;<br>халыкның террорчылык һәм экстремистик идеология күренешләренә түзеп тормау атмосферасын булдыруга юнәлтелгән иҗтимагый фикер формалаштыру. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары | 2017-202020 елларда, шул исәптән:<br>I этап: 2017-2018 еллар;<br>II этап: 2019-2020 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары: | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 6 757,2 сум тәшкил итә, шул исәптән: 2017 елда - 2 072,8 сум; 2018 елда-1 684,4 сум; 2019 елда-1 500, 0 сум; 2020 елда 1 500,0 сум. Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | 2020 елга Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру мөмкинлек бирәчәк:<br>- террорчыларны һәм экстремистларны җәзалауны гадел чара буларак бәяләгән халык өлешен 75% ка кадәр арттыру;<br>- хокук саклау органнарының терроризм һәм экстремизм күренешләре белән көрәшен җитәрлек чара буларак бәяләгән халык өлешен 50%ка кадәр арттыру |
| Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру | Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота. |

## 1. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы.

### 1.1. Төп проблемалар һәм аларны чишү юллары.

Россия Федерациясе Конституциясе, шәхес, җәмгыять һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өлкәсендә федераль законнар, Россия Федерациясенең 2009 елның 5 октябрендәге террорчылыкка каршы көрәш концепциясе, 2025 елга кадәр Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте Стратегиясе, шулай ук милләтара, динара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләүгә һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә юнәлтелгән башка стратегияләр, концепцияләр, нигезләр һәм нигезләмәләр Ярдәмче программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен нигез булып торалар.

Экстремизм - уртак куркыныч, һәм аның идеологиясен бары тик дәүләт һәм муниципаль институтларның, фәнни һәм мәгариф даирәләренең, массакүләм мәгълүмат чараларының һәм гражданлык җәмгыяте структураларының уртак каршылыгы гына җиңәргә мөмкин. Экстремизм үзенең барлык күренешләрендә гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгаруга китерә, иҗтимагый иминлекне какшата, конституциячел төзелеш, милләтара һәм конфессияара тынычлык нигезләренә яный.

Бүген Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районында татарлар - 12829 кеше (64,4%), чувашлар - 3829 кеше (19,2%), руслар – 3143 кеше (15,8%), башкалар – 119 кеше (0,6%) яши. Районда иҗтимагый-сәяси, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы тотрыклы, дустанә, конструктив хезмәттәшлек һәм төрле социаль төркем, милләт һәм дин вәкилләре арасындагы хезмәттәшлек белән характерлана. Экстремистик күренешләр күзәтелми. Җирле халык традицион булмаган ислам тарафдарларына тискәре карашта.

Татарстан Республикасында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш өлкәсендәге хәзерге вәзгыять киеренке булып калганга, Ярдәмче программа әзерләү һәм алга таба аны гамәлгә ашыру зарур.

Хәзерге вакытта террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш практикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый хәрәкәтләрнең һәм барлык гражданнарның тырышлыкларын берләштерүне таләп итә.

Әлеге чараларның үтәлеше Әлки муниципаль районы органнары алдында торган иң кискен проблемаларның берсе булган терроризмга каршы тору дәрәҗәсен күтәрү буенча уңай тенденцияләр булдыру юнәлешен хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, бу нәтиҗәдә гомуми куркынычсызлыкны ныгытуга турыдан-туры йогынты ясаячак.

## 2. Ярдәмче программаның төп максаты, бурычлары. Ярдәмче программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен, аны гамәлгә ашыру вакытын һәм этапларын тасвирлау

Ярдәмче программаның максаты - Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын, экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору нигезендә аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен, районда андый күренешләрне профилактикалау һәм кисәтү дәрәҗәсен күтәрү.

Ярдәмче программа максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү таләп ителә:

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ туфракта конфликтларны кисәтү һәм булдырмау;

- халыкның террорчылык һәм экстремистик идеология күренешләренә түзеп тормау атмосферасын булдыруга юнәлдерелгән иҗтимагый фикер формалаштыру.

Ярдәмче программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның терроризмга һәм экстремизмга каршы тору;

- толерант аң һәм үз-үзеңне тоту нигезләре буларак гражданнарның хокукый культурасының кирәкле дәрәҗәсенә ирешү;

-яшьләр арасында кешенең хокукларын һәм ирекләрен хөрмәт итү, этникара тынычлыкка һәм килешүләргә омтылыш принципларына, этномәдәни бер-береңне хөрмәт итү принципларына нигезләнгән дөньяга карашны һәм рухи-әхлакый атмосфераны формалаштыру.

Ярдәмче программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрне файдаланырга тәкъдим ителә:

- террорчыларны һәм экстремистларны җәзалауны гадел чара буларак бәяләгән халык өлеше;

- хокук саклау органнарының терроризм һәм экстремизм күренешләре белән көрәшен җитәрлек чара буларак бәяләгән халык өлеше.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру 2017-202020 елларда, шул исәптән:

I этап: 2017-2018 еллар;

II этап: 2019-2020 еллар.

Төп максат, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук ярдәмче программада каралган чараларны финанслау күләме Кушымтада тәкъдим ителде.

## 3. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программаны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 6 757,2 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

| Ел | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле бюджеты акчалары (мең сум) |
|---|---|
| 2017 | 2 072,8 |
| 2018 | 1 684,4 |
| 2019 | 1 500,0 |
| 2020 | 1 500,0 |

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру максатларында чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаларны файдалану күздә тотыла.

Финанслау күләме фаразланган характерда һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## 4. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

Заказ бирүче - Ярдәмче программа координаторы планлаштыру, хезмәттәшлек, координацияләү һәм үтәлешен гомуми контрольдә тота: ел саен ярдәмче программа чараларына максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, аны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын аныклый, чараларны үтәү өчен җаваплы башкаручылардан Ярдәмче программа үтәлеше турындагы белешмәләрне соратып ала.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеге булган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Чараларны финанслау Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар аша гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар ярдәмче программаның заказ бирүчесенә - Ярдәмче программаның координаторына хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр чаралар үтәлеше һәм үзләштерелгән акча чаралары турында мәгълүматны тиешле бюджетның үсә баручы нәтиҗәсе һәм тулаем алганда, хисап елына хисап бирәләр.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба - еллык хисап) хисаптан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты һәм башкаручылар тарафыннан төзелә, Әлки муниципаль районы башлыгына һәм Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йомгаклау

мәгълүматын формалаштыру өчен, хисаптан соң килүче елның 1 мартына кадәр йомгаклау мәгълүматын формалаштыру өчен җибәрелә.

Еллык хисап үз эченә ала:

- хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;

- билгеләнгән срокларда башкарылган һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;

- Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;

- чараларны үтәүгә бюджетка бүлеп бирелгән һәм башка акчалардан файдалану турында мәгълүматлар;

- җаваплы башкаручы тарафыннан Ярдәмче программага кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат;

-башка мәгълүмат.

Ярдәмче программага үзгәрешләр кертү билгеләнгән таләпләр нигезендә чараларның җаваплы башкаручысы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программа чараларын үтәү һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеген Әлки муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе утырышларында, Ярдәмче программасын гамәлгә ашыручы учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләрен тыңлап, даими рәвештә карап чыгу планлаштырыла.

## 5. Ярдәмче программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программа чараларын үтәү тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарының терроризмны һәм экстремизмны, радикаль дини агымнарны профилактикалау буенча эш рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, ксенофобия, милли һәм расадан түземсезлек, территориядә этник дискриминациягә каршы тору;

- милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү, этносоциаль комфортлылык дәрәҗәсен күтәрү;

- террорчылык һәм экстремистлык күренешләренең барлык фактларына түзеп тормау, шулай ук толерант аң, башка этник һәм конфессиональ бергәлек вәкилләренә уңай караш;

- яшьләр арасында этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту һәм үстерү;

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы халкы арасында интернационализм культурасы, татулык, милли һәм дини түземлелек таралу.

“2017-2020 елларга Әлки муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау”
Ярдәмче программасына кушымта

## Ярдәмче программа чаралары исемлеге

## "2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау»

| т/б № | Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Районның бюджет акчалары хисабына финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
| | 1.Мәгълүмати-пропаганда чаралары | | | | | | |
| 1.1 | Массакүләм мәгълү-мат чаралары аша терроризмга һәм экстремизмга каршы тору турында мәгълүмат яктырту | ӘМР АТК;<br><br>«Әлки хәбәрләре» –«Алькеевские вести» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2017-2020 даими | - | - | - | - |
| 1.2 | Террорчылыкка каршы юнәлешле тышкы реклама чараларын һәм күрсәтмә-агитация продукциясе (белешмәлекләр, листовка-лар, плакатлар, календарлар һ.б) әзерләү һәм урнаштыру | ТР ӘМР БК;<br><br>ӘМР АТК;<br><br>АТК АМР;<br><br>ТР ӘМР БК ЯСҺСБ | 2017-2020 даими | - | - | - | - |
| 1.3 | Районның барлык ведомство карамагындагы учреждение-ләрендә террорчылыкка кар-шы юнәлештәге мәгълүмати стендлар урнаштыру һәм яңарту | ТР ӘМР БК;<br><br>“ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ,<br><br>ӘМР АҖ | 2017-2020 квартал саен | - | - | - | - |
| 1.4 | Әлки районында җирле ҖМСда, Интернет челтә-рендә терроризмны профи-лактикалау, социаль әһәми-ятле кыйммәтләрне пропа-гандалау һәм тыныч | ӘМР АТК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе(килешү буенча);<br><br>«Әлки хәбәрләре» –«Алькеевские | 2017-2020 квартал саен | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | миллэтара һәм динара мөнәсәбәтләр өчен шартлар тудыру мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган материаллар әзерләү | вести» газетасы редакциясе (килешү буенча) | | | | | |
| 1.5 | Террорчылык идеологиясен таратуны кисәтү максатларында, мәгълумати-пропаганда йогынтысы өчен кешеләр күпләп җыела торган урыннарда тышкы реклама һәм җиһазлар урнаштыру. | ТР ӘМР БК;<br><br>ӘМР АТК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе(килешү буенча);<br><br>ТР буенча Рссия ФДКУ 105нче ЯСКБ, РТ буенча РФ ЯКХ 7 нче отряды (килешү буенча) | 2017-2020<br>даими | - | - | - | - |
| **2. Терроризм һәм экстремизмны профилактикалауны тәэмин итү** | | | | | | | |
| 2.1 | Иҗтимагый әһәмиятле соци-аль проектларны һәм програм-маларны гамәлгә ашыруга яшьләрне җәлеп итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | ТР ӘМР БК;<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ | 2017-2020<br>даими | - | - | - | - |
| 2.2 | Дини секталар һәм экстремис-тик оешмаларның законсыз эшчәнлегенә балаларны һәм яшүсмерләрне җәлеп итүгә юнәлдерелгән профилактик әңгәмәләр оештыру | Әлки районы рухание (килешү буенча);<br><br>Әлки районы имам-мөхтәсибе (килешү буенча) | 2017-2020<br>ярты елга бер | - | - | - | - |
| 2.3 | Террорчылыкка каршы яклау системасын оештыру мәсьәләләре буенча укыту, мәктәпкәчә һәм дәвалау учреждениеләре җитәкчеләре белән семинар-киңәшмәләр үткәрү | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>ТР буенча Рссия ФДКУ 105нче ЯСКБ, РТ буенча РФ ЯКХ 7 нче отряды (килешү буенча) | 2017-2020<br>һәр елның сентябрь аенда | | | | |
| 2.4 | Гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык янаулары килеп чыкканда халыкны | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча | 2017-2020<br>һәр елның<br>1нче кварталы | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтү | бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>ТР буенча Рссия ФДКУ 105нче ЯСКБ, РТ буенча РФ ЯКХ 7 нче отряды (килешү буенча) | | | | | |
| 2.5 | Терроризмга каршы көрәштә бердәмлек көненә (3 сентябрь) Халыкара тынычлык көненә (21 сентябрь) туры китерелгән сәяси тотрыклылык янауларына яшьләрнең каршы торуына багышланган чаралар һәм яшьләр акцияләре үткәрү | “ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР “Әлки районы мәдәният бүлеге” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ;<br><br>Әлки районы рухание (килешү буенча);<br><br>Әлки районы имам-мөхтәсибе (килешү буенча) | 2017 сентябрь<br>2018 сентябрь<br>2019 сентябрь<br>2020 сентябрь | - | - | - | - |
| 2.6 | Терроризмга һәм экстремизм-га каршы тору өлкәсендә җи-наятьләрне һәм хокук бозулар-ны ачыклау һәм булдырмау буенча профилактик чаралар комплексын эшләү һәм гамәлгә ашыру | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР АҖ БК | 2017-2020<br>елга 1 тапкыр | - | - | - | - |
| 2.7 | Халык, иҗтимагый берләшмә-ләр, хезмәт коллективлары белән үзара хезмәттәшлек итү, террористик характердагы җинаятьләрне кисәтүдә ирекле нигездә катнашу буенча чаралар оештыру | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР АҖ БК | 2017-2020<br>һәр елның<br>1нче кварталы | - | - | - | - |
| 2.8 | Террор куркынычларын вакытында ачу һәм профилактик чаралар күрү максаты белән территориядәге һәм критик инфраструктура объектлары тирәсендәге | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча); | 2017-2020<br>даими | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оператив хәлгә даими мониторинг ясауны тәэмин итү | | | | | | |
| 2.9 | Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча муниципаль комиссиянең профилактик эше | ТР ӘМР БК | 2017-2020 даими | - | - | - | - |
| 2.10 | Терроризмга һәм экстремизмга каршы профилактик эшне тәэмин итүче затлар өчен квалификация күтәрү курслары узу (террорчылыкка каршы комиссия әгъзалары, муниципаль хезмәткәрләр, авыл җирлекләре башлыклары, җәмәгать оешмалары, уку йортлары вәкилләре) | ТР ӘМР БК | 2017-2020 елга 1 тапкыр | - | - | - | - |
| 2.11 | Әлки муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе утырышын даими нигездә үткәрү | ӘМР АТК | 2017-2020 квартал саен | - | - | - | - |
| 2.12 | Терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча авыл җирлекләре утырышларын үткәрү | ӘМР АТК;<br><br>ТР ӘМР АҖ БК | 2017-2020 квартал саен | - | - | - | - |
| 2.13 | Экстремистик һәм террористик идеологиянең таралуы билгеләре булган Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге матеиалларны ачыклау механизмын эшләү һәм гамәлгә ашыру | Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>«Әлки хәбәрләре» –«Алькеевские вести» газетасы редакциясе (килешү буенча);<br><br>"ФОРПОСТ" “Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр оешмаларының Әлки ТҮ” МБУ(килешү буенча) | 2017-2020 даими | - | - | - | - |
| 2.14 | Хокук саклау органнары вәкилләрен чакырып террорлык актлары барлыкка килү куркы-ынычы янаган гамәлләр | Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2017-2020 ярты елга бер | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | турын-да укучылар белән профилак-тик әңгәмәләр оештыру | | | | | | |
| 2.15 | Гомуми белем бирү оешмаларында иҗтимагый һәм дини оешмалар, мәдәният учреждениеләре вәкилләре катнашында яшьләрне милләтара һәм динара толерантлык идеяләрен тәрбияләү буенча мәдәни-агарту һәм тәрбия чаралары үткәрү | Әлки районы рухание (килешү буенча);<br><br>Әлки районы имам-мөхтәсибе (килешү буенча);<br><br>“ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР “Әлки районы мәдәният бүлеге” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ. | 2017-2018<br>ярты елга бер | - | - | - | - |
| 2.16 | Белем бирү оешмаларының уку процессында яшьләрдә терроризм идеологиясен кабул итмәүне формалаштыру өчен терроризм идеологиясенең җинаятьчел асылын ачкан материаллар куллану. | “ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча);<br><br>“Алексеевск Аграр көллияте”ДАҺББУ филиалы | 2017-2018<br>даими | - | - | - | - |
| 2.17 | Терроризмга каршы тематика буенча кино күрсәтү | ТР ӘМР “Әлки киноучреждение " МБУ (килешү буенча) | 2017-2018<br>квартал саен | - | - | - | - |
| 2.18 | Социологик тикшеренүләрне оештыру һәм үткәрү террор-чылыкка каршы комиссиягә террористик янауларны про-филактикалау буенча башкар-ма хакимият органнары, җир-ле үзидарә органнары гамәл-ләренең нәтиҗәлелеген арт-тыру буенча тәкъдимнәр кертү һәм анализлау. | ӘМР АТК;<br><br>ТР ӘМР АҖ БК;<br><br>“ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча) | 2017-2020<br>ел саен | - | - | - | - |
| **3. Терроризмга һәм экстремизмга каршы көрәш чаралары** | | | | | | | |
| 3.1 | Массакүләм, бәйрәм чаралары вакытында хокук тәртибен | Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2017-2018<br>даими | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру. Үткәрү режимын тәэмин итү, техник ныгыту, саклау-тревога сигнализациясе чаралары белән җиһазландыру һәм аларны үткәрү урыннарын күзәтү. | | | | | | |
| 3.2 | Кеше күп була торган объектларда, шулай ук халык-ның тормыш-көнкүрешен тәэмин итүче объектларда тер-рорлык актлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү буенча көчләрнең һәм чара-ларның әзерлеген тәэмин итү буенча терроризмга каршы күнекмәләр һәм өйрәнүләр. | ӘМР АТК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2017-2020 квартал саен | - | - | - | - |
| 3.3 | Россия территориясендә эш-чәнлек тыелган террорчылык эшчәнлеге структураларына катнашы булган затларның район территориясенә үтеп керүенә юл куймау буенча чаралар | Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2017-2020 даими | - | - | - | - |
| 3.4 | Аерым мөһим объектларның, тормыш тәэмин итү объектларының, белем бирү һәм башка учреждениеләрнең һәм халык күп була торган объектларның террорчылык актларын булдырмау максатларында иминлек режимын көчәйтү чараларын гамәлгә ашыру | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>"Челтәр компаниясе"ААҖ "Чистай электр челтәрләре" (килешү буенча);<br><br>"Таттелеком «ААҖ Әлмәт ЗЭЭ Әлки цехы»(килешү буенча); | 2017-2020 даими | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР “Әлки районы мәдәният бүлеге” МКУ (килешү буенча) | | | | | |
| 3.5 | КФЙ торак фондын терро-ризмга каршы якланганлык предметына тикшерү | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>"Базарлы Матак идарә компаниясе” ҖЧҖ (килешү буенча) | 2017-2020<br>ел саен | - | - | | - |
| 3.6 | Район территориясендә файда-ланылмый яки билгеләү буен-ча файдаланылмый торган төзелеш һәм биналарда экстремистлык эчтәлекле әдә-биятын саклауны һәм кулла-нуны, утлы корал, сугыш ки-рәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр, шартлаткыч җай-ланмалар һәм көчле тәэсир итүче агулы матдәләрне туп-лауны һәм саклауны булдыр-мау максатында корылмаларга тикшерү үткәрү. | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР АҖ БК;<br><br>Оешма җитәкчеләре | 2017-2020<br>ел саен | - | - | - | - |
| 3.7 | Аудио-һәм видеоматериаллар, сәяси, идеологик, милли яки дини нәфрәт яки дошманлык кузгатуга юнәлтелгән басма продукцияне җитештерүче яки таратучы затларны ачыклау буенча чаралар күрү. | Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2017-2020<br>даими | - | - | - | - |
| 3.8 | Транспорт чараларын рөхсәтсез парковкалауны булдырмау өчен, уку һәм мәктәпкәчә белем бирү йортлары, сәламәтлек саклау | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча); | 2017-2020<br>даими | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләре, шулай ук массакүләм чаралар үткәрү урыннары янында яклау системасын камилләштерергә | ТР ӘМР АҖ БК | | | | | |
| 3.9 | Теркәлмәгән шәхесләргә арендага (файдалануга) бирүче шәхесләрне ачыклау. | ТР ӘМР БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча);<br><br>Әлки районы буенча ЭэМ миграция пункты (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР АҖ БК | 2017-2020<br>даими | - | - | - | - |
| 3.10 | - хәвефле сигнализация системасын монтажлау;<br>- металл детектор сатып алу;<br>- керү контроль системасын урнаштыру, монтажлау һәм көйләү (турникет);<br>- видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү,<br>- җиһазларга техник хезмәт күрсәтү эшләрен тәмамлау | "ТР Әлки районы мәгариф идарәсе" МКУ;<br><br>ТР ӘМР "Әлки районы мәдәният бүлеге" МКУ;<br><br>"ӘМР Финанс-бюджет палатасы" МКУ | 2017-2020 | 2 082,8 | 1 684,4 | 1 500,0 | 1 500,0 |
| 3.11 | Милләтара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләүгә юнәлдерелгән мәдәни-агарту чараларын үткәрү (фестивальләр, гастрольләр программалары, спектакльләр) | "ТР Әлки районы мәгариф идарәсе" МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР "Әлки районы мәдәният бүлеге" МКУ (килешү буенча) | 2017-2020<br>2017 апрель,<br>2018 март,<br>2019 сентябрь,<br>2020 сентябрь | - | - | - | - |
| 3.12 | Район китапханәләрендә террорчылыкка каршы тематика буенча әдәбият күргәзмәсе | "ТР Әлки районы мәгариф идарәсе" МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР "Әлки районы мәдәният бүлеге" МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР "ӘҖҮК" МБМУ (килешү буенча) | 2017-2020<br>һәр елның сентябрь аенда | - | - | - | - |
| 3.13 | Терроризмга каршы көрәштә | ТР ӘМР БК; | 2017-2020 | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бердәмлек көненә багышланган чаралар оештыру | ТР ӘМР БК ЯСhСБ;<br><br>ӘМР АТК;<br><br>“ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР “Әлки районы мәдәният бүлеге” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР "ӘҖҮК” МБМУ (килешү буенча);<br><br>«Әлки хәбәрләре» –«Алькеевские вести» газетасы редакциясе (килешү буенча) | һәр елның сентябрь аенда | | | | |
| 3.14 | Патриотик рухлы һәм физик яктан алга киткән яшь буынны тәрбияләүгә юнәлдерелгән, тормыш уңышының нигезе буларак шәхси иҗади хезмәткә юнәлдерелгән терроризм һәм экстремизмны профилактикалауның мөһим алшартлары чараларын күздә тоткан планнар һәм программаларны даими камилләштерергә. | ТР ӘМР БК;<br><br>“ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча);<br><br>ТР ӘМР “Әлки районы мәдәният бүлеге” МКУ (килешү буенча) | 2017-2020 даими | - | - | - | - |
| 3.15 | Яшьләргә гражданлык-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү өлкәсендә эйдәп баручы яшьләр берләшмәләре эшчәнлегенә мониторинг үткәрергә; аларның терроризм идеологиясенә каршы торуга юнәлдерелгән эшчәнлегенә ярдәм итәргә | ТР ӘМР БК;<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2017-2020 ел саен | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.16 | Мигрантлар арасында террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору максатында даими нигездә профилактик эш оештыру һәм үткәрү | ӘМР АТК;<br><br>ТР ӘМР АҖ БК;<br><br>Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2017-2020 даими | - | - | - | - |
| 3.17 | Җирле үзидарә органнарында Комплекслы план чараларын үтәү буенча турыдан-туры җитәкчелек йөкләнгән вазыйфаи затларны билгеләү | ӘМР АТК;<br><br>ТР ӘМР АҖ БК | | - | - | - | - |
| 3.18 | Комплекслы план чараларын үтәүнең барышы турында хисапларны ТР АТК аппаратына әзерләү һәм җибәрү | ӘМР АТК | 2017-2020 ярты елга бер | - | - | - | - |

**Файдаланылган кыскартулар исемлеге:**
**- ТР ӘМР БК - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты;**
**- ӘМР АТК-Әлки муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе;**
**- ӘМР Советының юридик бүлеге – Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының юридик бүлеге;**
**- ӘМР Советының оештыру бүлеге башлыгы урынб.-кадрлар эше өчен җаваплы зат – Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары;**
**- ТР ӘМР АҖ БК– Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары;**
**- РТ ӘМР БК ЯСһСБ - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге;**
**– Россия ЭэМ Әлки районы буенча бүлекчәсе - Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлеге;**
**-“ТР Әлки районы мәгариф идарәсе” МКУ - «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе»;**
**-“Алексеевск Аграр көллияте”ДАҺББУ филиалы - «Алексеевск аграр көллияте» ДАҺБУ филиалы;**
**- ТР ӘМР “Әлки районы мәдәният бүлеге” МКУ - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының " Әлки район мәдәният бүлеге «муниципаль казна учреждениесе;**
**- ТР ӘМР "ӘҖҮК” МБМУ - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының “Әлки җирлекара үзәк китапханәсе” муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе;**
**- ТР ӘМР “Әлки киноучреждение " МБУ - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Әлки киноучреждение» муниципаль бюджет учреждениесе;**
**- ”Челтәр компаниясе”ААҖ “Чистай электр челтәрләре” - «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте «Чистай электр челтәрләре»;**

ттелеком «ААЖ Әлмәт ЗЭЭ Әлки цехы» - «Таттелеком " ачык акционерлык җәмгыятенең Әлмәт зонасы электр элемтәсе Әлки цехы»;
Базарлы Матак идарә компаниясе" ҖЧҖ - "Базарлы Матак идарә компаниясе" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;
- Әлки районы буенча ЭэМ миграция пункты - Әлки районы буенча Эчке эшләр Министрлыгының миграция пункты;
-"ФОРПОСТ" "Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр оешмаларының Әлки ТҮ" МБУ - "ФОРПОСТ җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр оешмаларының Әлки территориаль үзәге" муниципаль бюджет учреждениесе;
- ТР буенча Рссия ФДКУ 105нче ЯСКБ, РТ буенча РФ ЯКХ 7 нче отряды - Татарстан Республикасы буенча Россия Федераль дәүләт казна учреждениесенең 105 нче янгын сүндерү-коткару бүлеге, Татарстан Республикасы буенча Россия Федераль янгынга каршы хезмәтенең 7 нче отряды.